РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2026 елның 27 марты № 14

Түбән Кама шәһәр Советының "Түбән Кама шәһәре территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турындагы Нигезләмәне раслау хакында" 2021 елның 18 ноябрендәге 60 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 32 статьясындагы 2 өлешенең 29 пунктының «д» пунктчасының үз көчен югалтуын тану хакында» 2026 елның 20 февралендәге 23-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1.Түбән Кама шәһәр Советының «Түбән Кама шәһәре территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында Нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 18 ноябрендәге 60 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар 2026 елның 01 сентябреннән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә рәсми рәвештә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыгын үстерү буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры
вазыйфаларын башкаручы,
Мэр урынбасары

М.В. Камелина